КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 декабрь г.Казань № 1310

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 2 октябрь, 945 нче карары белән расланган Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 2 октябрь, 945 нче карары белән расланган Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында, VIII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«VIII. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) өчен төп күрсәткечләр
һәм аларның максатчан мәгънәләре, индикатив күрсәткечләр

8.1. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру эффективлыгының һәм нәтиҗәлелегенең төп күрсәткече – 2022 – 2024 елларга иң чик мәгънәсен 17,3 литрдан күбрәк яки аңа тигез итеп билгеләп, база елына (2015 елга) карата балигъ булган халыкның җан башына алкогольле продукцияне (сырадан тыш) закон нигезендә ваклап сатуны биш проценттан да артыкка киметүне булдырмау.

8.2. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру эффективлыгының һәм нәтиҗәлелегенең индикатив күрсәткечләре:

1) хисап чорында планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

2) хисап чорында контрольдә тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларында расланган параметрларга туры килүен яки контрольдә тотылучы объектның мондый параметрлардан читкә китүен ачыклау нигезендә планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

3) хисап чорында хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

4) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларының һәр төре буенча хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

5) хисап чорында үзара дистанцион хезмәттәшлек итү чараларыннан файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

6) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

7) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләр саны;

8) хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

9) хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

10) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм прокуратура органнары тарафыннан килештерелмәгән гаризалар саны;

13) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектларның гомуми саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган, риск категорияләренә кертелгән контрольдә тотылучы объектларның риск категорияләрендәге һәрберсе буенча саны;

15) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

16) хисап чорында исәпкә алынган һәм аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы затлар саны;

17) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

18) хисап чорында контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) орган тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләр саны;

19) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән, карап тикшерү йомгаклары буенча контрольдә тотучы органның карарын тулысынча йә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органнарның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны;

20) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

21) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре

(гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән, белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;

22) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.

8.3. Төп күрсәткечкә анализ календарь ел йомгаклары буенча әзерләнә торган төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру һәм мондый контрольнең (күзәтчелекнең) эффективлыгы турындагы докладта ясала.».

2. Бу карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин